وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№10 (153). 7 сентябрь 2012 / 20-шәүвәл-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ





Бирүче кул саекмасын ▷2◁





"Дөнья кумыйбыз!" ▷3◁





Яшьлекнең кадерен белик! ▷4◁


# КАЗАН МӨСЕЛМАН КИНОФЕСТИВАЛЕ ИСЛАМ ТРАДИЦИЯЛӘРЕНЕҢ КҮПГАСЫРЛЫК ҺӘМ ДӨНЬЯКҮЛӘМ РУХИ-ӘХЛАКЫЙ ПОТЕНЦИАЛЫН АЧАРГА ЯРДӘМ ИТӘ

**Әссәламегаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкатүһү!**

Фестивальдә катнашучылар һәм кунаклар, сезне сәламләвемә бик шатмын. Заманча кинематография, аерым алганда, Казан мөселман кинофестивале - Ислам традицияләренең күпгасырлык һәм дөньякүләм рухи-әхлакый потенциалын ачарга ярдәм итүче, дәвам итүче мәдәни зур чара. Фестивальнең әһәмияте кешеләр өчен мөһим мәсьәләләргә тиз арада игътибар юнәлтүче динамик сәнгать - киноны киң җәмәгатьчелеккә җиткерүендә дә чагылыш таба. Шуңа да, Казан мөселман кинофестивале мөселман өммәтен борчыган темаларны кино сәнгате аша күрсәтеп, дөньякүләм иҗтимагый диалог коруына өметләнәбез.

Шулай ук, иҗади эшләрен бу фестивальдә тәкъдим иткән сәнгатькәрләргә рәхмәтемне белдерәсем килә. Ислам - дөнья мәдәниятенең аерылгысыз бер өлеше, Җир йөзендә яшәүче миллиард ярымнан артык кеше өчен төп юнәлеш булып тора. Бу кешеләр тормышы турында сөйләргә кирәк, алар хакында эндәшми калырга ярамый. Аллага шөкер, бүгенге көндә иҗатларын мөселманнарга багышлаган талантлар бар. Һәм шушы талантлар катнашкан фестивальнең милләтара һәм динара дуслык-татулык белән аерылып торган Татарстан башкаласында үткәрелүе безне аеруча шатландыра.

Ислам дине интеллектуаль һәм мәдәни үсешне хуплый. Бүген дә бу үзенчәлекне дәвам итеп, Казан мөселман кинофестивалендә катнашучыларга яхшы, уңай бәяләмәләр алуларын, ә тамашачыларга яңа кино сәнгате казанышларын күрүләрен һәм күңелләре рухи кыйммәтләр белән тагын да баюын телим.

**Үзәкләшкән дини оешма -**
**ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,**
**мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ**

# ГОШЕР КӨНЕ

**Уңыш җыю вакыты - көз җитте. Эшчән кеше өчен мул уңыш җыеп алу - зур бәхет ул. Ләкин муллыкның төп сәбәбе турында да онытмаска кирәк. Гадел хезмәттән тыш моңа табигать тә тәэсир итә. Нәкъ менә шуңа күрә мөселманнар Аллаһы Тәгаләгә догалары белән мөрәҗәгать итәләр: яңгыр кирәк икән, яңгыр сорыйлар, аяз, болытсыз һава торышы кирәк икән - кояшлы көннәр сорыйлар. Мул уңыш җыеп алу өчен яхшы һава торышының Аллаһы Тәгалә мәрхәмәте белән бирелгәне көн кебек ачык. Бу рәхмәткә ирешеп, киләчәктә дә мул уңыш җыеп алу мөмкинчелегенә ирешү өчен, Раббыбыз кушканны үтәп, гошер сәдакасын бирергә кирәк.**

Коръәни-Кәримдә болай диелә: "Әй, мөэминнәр, җыйган малларыгызның иң затлыларын гына вә сезнең өчен җирдән чыгарганнарыбыздан (сәдака, хәер, зәкят биреп, Аллаһ юлында) сарыф итегез. Күз йомып (чыраегызны сытып, җирәнеп кенә, теләр-теләмәс кенә) алырдай затсыз малны бүләккә бирергә тырышмагыз (үзегезгә ошамаган, гамәлгә яраксыз мал хәергә бирелмәс). Белеп торыгыз, Аллаһ чиксез бай һәм мактауга лаек" ("Бәкара (Сыер)" сүрәсенең 267 нче аяте).

Нәрсә соң ул гошер? Бу гарәп сүзе "уннан бер өлеш" дип тәрҗемә ителә. Революциягә кадәр татарларда гошер җыю гадәти эш булып саналган - гошер сәдакасы мәчетләр эшчәнлеген тәэмин итүгә тотылган. Һәм бүген бу мөһим дини гадәтне яңадан торгызырга кирәк, чөнки авыл җирлегендәге күпчелек мәчетләрнең ишекләре акча булмау сәбәпле ябык торалар.



Элек гошер җыю бәйрәм рәвешендә үткәрелгән, чөнки уңыш Аллаһы Тәгалә рәхмәте буларак кабул ителгән. Совет чорында гошер бәйрәмнәре уңыш бәйрәмнәре белән алыштырыла һәм бу бәйрәмнәрдә, кызганыч, уңышның төп сәбәпчесе - Аллаһы Тәгаләне искә алмыйлар.

Татарстанда соңгы елларда гошер сәдакасын җыюга берникадәр игътибар итә башладылар - республикакүләм Гошер көнен, авылларда гошер бәйрәмнәрен үткәрәләр. Шуны аңларга кирәк: гошер сәдакасын бирү - дини бурыч. Бу фарыз гамәл, шуңа да гошерне ачыктан-ачык бирергә була. Гошерне тормышыбызга кайтару бәрәкәт артуга китерәчәк, чөнки гошер фәкыйрьләргә, мәчет һәм мәдрәсәләр файдасына бирелә, Аллаһы Тәгалә юлында тотыла. Гошер сәдакасын бирү - киләчәктә мул уңыш алуга ышаныч булып тора. Рәсүлебез Мөхәммәт (сгв) болай дигән: "Әгәр дә өммәтем гадел булса, зәкят һәм гошер сәдакасын түләүдән туктамаса, аңа хәвеф-хәтәрләр төшмәс. Шулай эшләмәгән очракта, корылык һәм ачлык белән сыналачаклар".

Аллаһы Тәгалә рәхмәтенә ирешүне күзаллап, сентябрь ахырында авылларда Гошер көннәрен үткәрергә онытмаслар дип өметләнәбез.

***Вәлиулла хәзрәт***
***ЯКУПОВ***

# Вәлиулла хәзрәт турында истәлекләр

**"Көнчыгыш Европа мөселман өммәтенең үсешен һәм бигрәк тә Татарстанда аның бүгенге халәтен объектив рәвештә күзәтүче ирексездән түбәндәге, бәлкем, аның өчен көтелмәгән нәтиҗәгә килә: дини күзлектән караганда Идел-Урал төбәге асыл Исламның хәзинәсе буларак саклана алган. Бабаларыбыз Исламны сәхабәләрдән кабул итүләре, алар арасында табигыйннар, тәбгу-табигыйннар булуы халкыбызда Исламның асыл тәгълиматын сакларга мөмкинлек биргән. Бүген дә без тышкарыдан һөҗүм итүче зиндыйлыкка, фасикълыкка, экстримистлыкка баткан "мөселман" агымнары тәэсиренә бирелмичә, бабаларыбыз саклаган, Пәйгамбәребездән (сгв) килгән саф асыл Исламда булуыбызны дәвам итсәк икән".**

Мәрхүм Вәлиулла хәзрәт үзенең "Ислам асылына кайту" исемле китабына кереш сүздә шушыларны яза. Бу сүзләр аның, милләткә, ислам диненә карашын, тормыштагы максатын, яшәү рәвешен күрсәтә. Чынлап та, ул безнең халыкта ислам дине сәхабәләрдән иреклe рәвештә кабул ителгән һәм ислам динен пәйгамбәребез Мөхәммәд саллә-ллаһу галәйһи үә сәләм ничек тараткан, дин шул асыл рәвештә сакланган дип саный иде. Һәм шул асыл динне торгызу өстендә армыйталмый эшләде, хәтта, күргәнебезчә, үзен корбан итү бәрабәренә.

Без Вәлиулла хәзрәт белән 1994 елдан, мин "Йолдыз" мәдрәсәсендә ректор булып эшли башлаганнан бирле таныш. Баштарак мәдрәсә ректорлары буларак аралаша идек. Аннары, 1998 елдагы берләштерү корылтаеннан соң ул мөфтинең беренче урынбасары булып эшләде һәм мин инде аның җитәкчелегендә эшләдем. Ул эшли иде. Бу сүземә басым ясап әйтәсем килә: бүген аны тәнкыйтьләүчеләрдән аермалы буларак, ул тырышып эшли иде. Дөресен әйтергә кирәк, ул үз максатын тормышка ашырырга тырышты. Шуңа күрә аның белән эшләү бер үк вакытта авыр да, җиңел дә иде. Авыр иде, чөнки мин болай телим дип кенә нәрсәдер эшләп булмый. Шул ук вакытта үзеңчә эшләр өчен, аны үзеңнең дөреслегеңә ышандырырга кирәк һәм хәзрәтне ышандырып була иде. Җиңел иде, чөнки үзара бәхәстә икең дә бер фикергә киләсең һәм эшли торган эш тә тиешенчә эшләнә. Ягъни эшли торган эштә билгесезлек юк иде. Мәсәлән, Имамнарның белемен күтәрү курсларын оештырганда аның белән күп бәхәсләшергә, әһәмиятен аңлатырга туры килде, менә оештыргач


*(Ахыры 2 нче биттә.)*


## ЯҢАЛЫКЛАР

**БИЕКТАУДА МӘЧЕТЛӘР САНЫ АРТА**

**24 август көнне Биектау районының Чыпчык авылында яңа мәчет ачылган иде.** Бүгенге көндә исә янә берничә мәчет төзелеше ахырына якынлашып килә. Беренчесе - Биектауның үзендә, икенчесе - Шәпше авылында, өченчесе исә Берёзка авылында. Әлеге өч мәчетне, мөхтәсиб билгеләп үткәнчә, Корбан гаетенә кадәр ачарга ниятлиләр.

**МӘЧЕТКӘ КӨТЕЛМӘГӘН КУНАКЛАР КИЛГӘН**

**3 сентябрьдә Түбән Кама Җәмигъ мәчетенә Түбән Кама шәһәренең "Нефтехимик" командасы хоккейчылары килгән.** Башкалардан күрер күзгә аерылып торган әлеге "кунаклар" тыныч кына имам-хатыйб Йосыф хәзрәт Дәүләтшинның вәгазен тыңлаганнар. Тыгыз графикларында экскурсияләр өчен вакыт булмаса да, мәчеткә - Аллаһы йортына килергә вакыт тапканнар.

Мөселманнар аларга җәрәхәтләнүләрсез җиңүләр тели һәм шул җиңүләре аркылы күңелләре, горурлык-тәкәбберлек түгел, ә Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт хисләре белән тулса иде.

**ӘГЕРҖЕ МӨХТӘСИБӘТЕ УКУЧЫЛАР БЕЛӘН ОЧРАШТЫ**

**3 сентябрьдә Әгерҗе районының 2 нче мәктәбендә, "Терроречылыкка каршы көн" уңаеннан, православие һәм мөселман дин әһелләре IX-XI сыйныф укучылары белән очрашу оештырды.** Әлеге чарада район имаммөхтәсибе Ранил хәзрәт Якупов җәмгыятебезнең иминлеге, тынычлык турында вәгазь сөйләгән, мәктәп укучыларын кызыксындырган сорауларга җавап биргән. Хәзрәтнең узган атнадагы җомга вәгазе дә "Террорчылыкка юл юк!" дип аталган булган.

Район мөхтәсибәтеннән хәбәр итүләренчә, 14 сентябрьдә мәктәп укучыларын янә җыеп, террорчылыкка каршы махсус акция үткәрү планлаштырыла.

**I ЯКУПОВ УКУЛАРЫ УЗДЫ**

**4 сентябрьдә тәүге тапкыр Якупов укулары дип аталган фәнни-гамәли конференция уздырылды.** Әлеге чара Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан РИУ белән берлектә Вәлиулла хәзрәт истәлегенә багышлап, аның дини, иҗтимагый мирасына җәмәгатьчелек игътибарын юнәлтү, дини мәгариф өлкәсендә алып барган эшчәнлеген дәвам итү юлларын барлау максатыннан оештырылды.

Конференциядә Вәлиулла хәзрәтнең дини-фәнни хезмәтләре җыентыгын бастыру, музеен булдыру турында тәкъдимнәр яңгырады. Шулай ук каләм ияләре өчен Вәлиулла хәзрәт Якупов исемендәге махсус премия булдыру һәм дини уку йортларында аның эшчәнлегенә багышланган фәнни хезмәтләр язу турында әйтелде.

Якупов укулары дип аталган фәнни-гамәли конференцияне ел саен уздыру күздә тотыла.

***Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды***

# Вәлиулла хәзрәт турында истәлекләр

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

һәм имамнарны укыту дәверендә күп мәсьәләләрне бергә чиштек. Безнең мәдрәсәне прокуратура ябарга теләгәндә, судлашып йөргән вакытларда да, Вәлиулла хәзрәт иң беренче ярдәмче, яклаучы булды. Мәдрәсә уставлары язганда да ул үзенең киңәшләре белән ярдәм итте. Бәлки болай әйтүем бик үк дөрес тә түгелдер, чөнки Диния нәзарәтенә кергән барлык оешмаларның да уставларының авторы ул дисәм, дөресрәк буладыр. Узган гасырның 90 нчы елларында чит илләрдән кергән юнәлешләр никадәр генә көчле, акчалы булсалар да уставларда үзебезне? халык мең елдан артык тоткан хәнәфи мәзһәбе юнәлешен саклап калды. Вәлиулла хәзрәт үзенең хезмәтләрендә: "Татарлар тота торган хәнәфи мәзһәбе ислам диненең иң толерант булган юнәлеше", дип әйтә килде.

Диния нәзарәтенең мәгариф системасы оешуга, аның бүгенге көндәге эшчәнлегендә дә Вәлиулла хәзрәтнең өлеше бик зур. Нинди генә кимчелекле яклары булса да, Диния нәзарәтенең мәгариф системасы хәзер бар һәм ул бүген дә гамәлдә. Ә инде аны камилләштерү мәсьәләсенә килгәндә, ул һәрвакыт дәвамлы булачак. Мисал өчен, бүгенге Россия мәгариф системасын алып карасак, ул әле бүген дә камилләшүен дәвам итә.

Илдус хәзрәт Фәиз мөфти булып сайлангач, ул Диния нәзарәтенең үзе нигезләгән мәгариф системасын алып барды. Кайберәүләрнең хәзер мәдрәсәләр таралыр инде дип фараз кылуларына карамастан, мәдрәсә системасы сакланды, фәкать таләпләр генә артты. Элек гакыйдә, фикъһе мәсьәләләрендә үзебезнең традицион хәнәфи мәзһәбенә игътибар аз булса, практикада кайбер мәдрәсәләрдә традицион ислам төшенчәсе, гомумән, динсезлек дәрәҗәсендә аңлатыла иде, хәзер исә төпле итеп, меңьеллык тарихыбызны истә тотып, бер юнәлештә алып барыла.

Узган гасырның 90 нчы елларында Советлар Союзын сүгү, аны гел кимчелекле итеп күрсәтү модага керде. Шушы модага ияреп күпләр илне таратуда үзләренең өлешләрен кертте. Һәм еллар үткәч, Совет иле гел кимчелектән генә тормаган, ул вакытта нindidер яхшылыклар да булганлыгы күренде. Шуның кебек Вәлиулла хәзрәт исән вакытта аны сүгү модага керде. Хәтта мөхтәсибләр, җыелышып, аны беренче урынбасар вазифасыннан да алдылар. Күпләргә Вәлиулла хәзрәт беренче номерлы дошман булып күренде. Вәлиулла хәзрәтнең үлемендә турыдан-туры катнашмасалар да, үз вакытында В.Якуповны эшеннән алу мәсьәләсен оештыручылар, эшеннән алырга дип кул күтәрүчеләр, шушы үтерүгә беренче булып заказ бирүчеләр. Мин аларга: "Бүген Вәлиулла хәзрәт юк, сезгә комачаулаучы юк, нишләп дин күтәрүдә тырышлыгыгыз артмадың" - дип сорау бирер идем.

Вәлиулла хәзрәтнең дингә, милләткә булган мөнәсәбәтенә бәя бирергә теләсәк, аның үзенең сүзләрен искә төшерүебез урынлырак булыр:

"Хәнәфи мәзһәбенә килгәндә, без аны бүген ни өчен тотарга тырышабыз? Кайберәүләр уйлаганча: безне? бабаларыбыз мең елдан артык тоткан өчен түгел. Безнең өчен аның хаклыгы әһәмиятле - Әбу Хәнифә хәзрәтләре табигыйн булган, ягъни сәхабәләрне күреп алардан гыйлем алган. Әлбәттә, ул үзенең табигыйн статусы бәрабәренә шәригать белемен үзеннән соң килүче галимнәргә караганда яхшырак аңлаган. Шуның өчен кем генә булмасын - Бохари, Ибне Тәймия һәм башкаларның сүзләре хәнәфи мәзһәбеннән өстен була алмыйлар. Димәк, без татарлар булу сәбәпле генә хәнәфи түгелбез. Бу мәзһәбтә Пәйгамбәр саллә-ллаһу галәйһи үә сәләм өйрәтмәләре и? мөкәммәл рәвештә чагылыш тапканга, без - хәнәфиләр".

Бүген Вәлиулла хәзрәт турында күп язалар: аны Мәрҗаниләргә тиң шәхес диеп мактаучылар да бар, аны кяферлеккә чыгарып түбәнчелеккә төшерергә теләүчеләр дә бар. Бу ике фикер дә аның гади намаз укучы гына булмаганын күрсәтә. Ул бөтен көчен хәнәфи мәзһәбен таратуга куйды: алда үзе әйткәнчә, ата-бабаларыбыздан калган өчен түгел, бәлки Әбу Хәнифә пәйгамбәребез Мөхәммәдкә (сгв) якынрак чорда яшәгән өчен, аның аңлатуының хаклыгына төшенгән өчен. Димәк, аны имам Әгъзам Әбу Хәнифәнең шәкерте дип санарга була. Остазына да шундый ук капма-каршы булган бәя бирәләр: кемдер аны пәйгамбәр дәрәҗәсендә санаган, кемдер кяферлектә гаепләгән. Икесенең дә үлемнәре дә залим кулыннан була. Димәк, шәкерте остазына лаек. Аңа дөрес бәя бирер өчен вакыт кирәк. Мин фәкать аның гади булганлыгы турында гына әйтә алам. Аның белән бәхәсләшергә дә була иде, ошамаган нәрсәләреңне әйтеп аны сүгәргә дә була иде, артыннан ук кочаклашып килешергә, берни булмаган кебек сөйләшергә дә була иде. Башланган сүзне бүлми иде, үзе ошатмаса да, фикерне ахырынача тыңлый иде, бу миңа каршы әйтте дип, үч сакламый иде. Бәлки аның шушы сыйфатлары хәзрәтнең гади булмаганлыгын күрсәтә торгандыр. Аллаһ Белүчерәк.

***Рөстәм хәзрәт ШӘЙХИВӘЛИЕВ,***
***ТР мөселманнары Диния нәзарәте Президиумы әгъзасы, Кама буе төбәге казые***

# Бирүче кул саекмасын

**Бу дөньяда барыбыз да сынау уза. Киң күңеллелеккә, миһербанлыкка, кешелеклелеккә. Фәрештәләребез барысын да хисап дәфтәребезгә язып бара.**

Үстергән уңышларның уннан берен уңышны җыйган көндә хакын (гошерен - уннан бер өлешен) бирү мәҗбүри. Зәкят итү - малыбызны хәрамнан чистарту, дигән сүз дә ул. Аллаһы Тәгалә аның бер өлешен мохтаҗларныкы, ятимнәрнеке дип бүлеп куйган. Хәер, авыр хәлләләргә ярдәм күрсәтү кешелеклелек сыйфатын да күрсәтә бит әле. Көз җитүгә мөселманнар мәчетләргә, мәдрәсәләргә гошер сәдакасы китерә башлыйлар. Элек безнең Кече Кирмәндә (Мамадыш районы) умарта тотучылар ятимнәргә, гариn-горәбәләргә бал кертәләр иде. Ачыктан-ачык зәкят бирү, гошер сәдакасы җыю моннан егерме ел чамасы элек башланды. Арташ авылында аны бәйрәм итеп уздыру гадәткә кергән. Быел да Мәскәүдән, Казаннан, Мамадыштан олы кунаклар чакырып зурлап билгеләп үттеләр. Казандагы Рамазан мәчете имамы, Россия ислам университеты мөгаллиме, күп кенә китаплар авторы Солтан хәзрәт Морадыймов, Мамадыш районы имам-мөхтәсибе Илһам хәзрәт Миңнегалиев, район мәдрәсәсе директоры Габдрахман хәзрәт Хәбибуллин, әйләнә-тирә авылларның имамнары килгән иде. Кунаклар башта Ханнар зиратында булып, әрвахлар рухына дога кылды. Аннан Арташ авылына юнәлделәр. Мәчет каршындагы махсус урынга халык капчык-капчык бәрәңге, кишер, чөгендер, кабак кебек яшелчәләр китергән иде. Ишек алдына казан асып, пылау пешерергә куйдылар. Мәчет эчендә чәй табыннары әзерләнде. Бәйрәмне авыл имамы Рифат хәзрәт ачып җибәрде, кунаклар белән таныштырып чыкты. Аннан соң Солтан хәзрәт белән Илһам хәзрәт зәкят бирүнең фарыз гамәл булуы турында тирән эчтәлекле вәгазь сөйләде. Мәскәүдән махсус шушы бәйрәмебезгә авылда туып-үскән күренекле язучы һәм журналист Нәзифә Кәримова да кайткан иде. Ул үзенең изге теләкләрен җиткерде. Бәйрәм соңында Коръән укып, сәдакаларга дога кылынды. Гошергә җыелган яшелчәләр мохтаҗларга, мәдрәсәләргә тапшырылачак.

**Миңневәрис МИНГАЛИЕВ**



# Татарстан депутатларын хәзерге Татарстанда Исламдагы төп тенденцияләр һәм юнәлешләр белән таныштырдылар

**ТР Дәүләт Советы комитетының 4 сентябрь утырышы башка көннәрнекенә ошамаган иде: Россия ислам университеты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин депутатлар алдында "Хәзерге Татарстанда ислам: төп тенденцияләр һәм юнәлешләр" дигән темага лекция белән чыкты. Ул аны Татарстанда 19 июльдә булып узган вакыйгалар нисбәтеннән оештырылган сессиядә яңгыратылган лекциянең дәвамы дип билгеләде.**

Ул Исламның дөньякүләм дин буларак бердәм дин икәнлеген һәм X гасырга аның, мәзһәбләр (катгый дини чикләр) формалашып, бердәм институт буларак яши башлавын билгеләп үтте. Хәзерге яшьләрнең мәзһәбләрне танымау очраклары барлыгын хәбәр итеп, мәзһәбләрнең дини яңарыш вакытында бигрәк тә мөһим булуын белдерде.

"Без бүген мәзһәбләр һәм традицион ислам турында күп сөйлибез", - дип, РИУ ректоры мәзһәбләрнең Исламның бердәмлеген саклавын ассызыклап үтте. Ул Багдад илчелеге килгәч, 922 елда ук, бабаларыбызның хәнәфи мәзһәбе тарафдарлары булуын, традицияләрнең шул вакыттан бирле килүен белдерде.

Рәфыйк Мөхәммәтшин фикеренчә, җәмгыятьнең дөньявига һәм динигә бүленүе дә проблемалар китереп чыгара. Конфессиональ мөнәсәбәтләрне, сәясәтне ничек корырга дигән сораулар туа. "Мөселманнар мәсьәләләренә дәүләттә зур игътибар бирелергә тиеш", - дип белдерде ректор.

"Традицион Исламга каршы килүчеләр шактый. Каршылар моны уйлап табылган, диләр. Яшьләр исә "без Коръән һәм Сөннәт буенча яшибез" дип сөйли", - диде Рәфыйк Мөхәммәтшин XVIII гасырга кадәр "традицион ислам" һәм "чиста ислам" төшенчәләренең булмавын, "чиста ислам" төшенчәсенең нәкъ менә шушы гасырда, Согуд Гарәбстанында ваһһабчылык барлыкка килү һәм аның дәүләт идеологиясенә әйләнүе белән аңлатып үтте.

"Традицион Ислам - ул традицияләргә ияру, - дип аңлатып үтте депутатларга Р.Мөхәммәтшин. - Ә "чиста ислам" тарафдарлары милләткә бүленешне дә, традицияләрне дә кире кага. Алар дөньяны акка, карага гына аера. Хәзерге яшьләр радикализация яклы". Ул яшьләр өчен традицион Исламның кызыклы булмавын, аларның күз алдында мәчеттә утыра һәм йолаларны үти торган бабайның күз алдына килеп басуын билгеләп үтте. "Алар хәнәфи мәзһәбен бер төркем примитив йолалар дип бәяли", - диде Р.Мөхәммәтшин.

Аның сүзләренчә, хәнәфи мәзһәбендә исламга каршы килми торган гореф-гадәтләр һәм йолалар үткәрү рөхсәт ителә. "Чиста ислам" тарафдарлары инкяр иткән мәетнең "өчесе"н, "җидесе"н үткәрү, Пәйгамбәребезнең (сгв) туган көнен билгеләп үтү дә шушыңа керә.

Ректор әйтүенчә, "чиста ислам" тарафдарларының фикерләре моноконфессиональ җәмгыять өчен генә яраклы. Мондый җәмгыятькә ия булган илләрдә белем алып кайткан яшьләр буш урында проблемалар тудыра. "Алар безнең милли тамырлардан аерылган, ата-анасын кяфер дип атый. Үзенең күңелен "мин Коръән һәм Сөннәт буенча яшим" дип юата. Алар гамәлдә булган институтларны тәнкыйтьли", - дип, ректор дәүләт тарафыннан конфессиональ сәясәт субъектларын билгеләргә тиешлеген хәбәр итте.

Рәфыйк Мөхәммәтшин лекциядә шулай ук яңа уку елында Татарстан мәктәпләренең IV сыйныф укучылары өчен "Диннәр мәдәниятләре һәм дөньяви этика нигезләре" предметы укытыла башлавын да билгеләп үтте. Социологик сораштыру нәтиҗәләре буенча 30 яшькә кадәр булган яшьләр теге яки бу дин тарафдары булуын хәбәр иткән. "Яшьләрнең дин белән кызыксынуы бар. Алар дингә кагылышлы белем алу өчен чыганаклар табарга тиеш", - диде ректор.

"Без яшьләргә мөселманнар һәм артыбызда күп гасырлык традицияләребез торуын әйтергә тиешбез. Моннан башка радикализация килеп чыгуын да көт тә тор", - дип, Р.Мөхәммәтшин урыннарда дини мәсьәләләр белән шөгыльләнүче белгечләр булырга тиешлеген, бүгенге көндә районнарда вазгыятьне анализлап, бәя бирүче булмаганлыгын ассызыклап үтте.

ТР Мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары Данил Мостафин исә депутатларга яңа предметның үзенчәлекләре турында сөйләде. Дәреслрнең эпизодларга нигезләнгән хикәяләрдән торган дәреслекләр буенча алып барылуын, төп диннәр турында мәгълүмат бирүдә укытучыдан зур осталык соралуын билгеләп үтте. Предметның төп максаты башка мәдәниятләрне һәм диннәрне хөрмәт итүгә ирешү икәнлеген белдерде. Бастырып чыгарылган дәреслекләр моны эшләргә ярдәм итә.

***Римма ГАТИНА***

МИЛЛӘТТӘШ

# "ДӨНЬЯ КУМЫЙБЫЗ!"

**Күптән түгел декоратив-гамәли сәнгать әсәрләре арасында үткәрелгән "Сөйкемле Шүрәле" Бөтенроссия иҗат бәйгесендә җиңгән балаларны котларга Пензага баргач, бик тә кызыклы авылга тап булган идек. Ул - Октябрьское, Пенза өлкәсенең Неверкин районында урнашкан 1654 кеше яши торган чеп-чи татар авылы. Тырыш, мәрхәмәтле, ихлас күңелле, ярдәмчел кешеләр яшәгәнгә күрә, аны икенче төрле "Мәрхәмәтлеләр авылы" дип тә йөртәләр. Өстәвенә, Октябрьское - ислам кануннарын үтәп яши торган, үз акчасына мәчетләр торгызган сала да ул...**





Исенская Полянка, Ерыклей, Аккүл, Мазарлы - болар Октябрьскоеның тагын да борынгырак атамалары. Татарлар бу якларга Пётр Беренченең указы нигезендә чуаш авылы янына килеп утырган, диләр. Хак булса, заманында авылга җиде мәчет хезмәт иткән, һәрберсе каршында мәдрәсәләр эшләп килгән. Иман йортлары революциядән соң юкка чыгарылгач, мәрхәмәтлеләр авылы дин бетүгә юл куймый. Халык үзенә купшы йорт-кура җитештерү урынына өч иман йорты торгызып куя: алар Черкиле, Урта, Тау мәчетләре. Биредә рамазан аенда дини курслар уздырыла, ифтар ашлары гөрли. Хатын-кызлар гарәп теленә өйрәнә. Иң мөһиме - бу өч мәчет бүген дә халыкның сәдака акчасына яши. "Безнең дөнья кумау, тормышка разый, үз көнебезгә канәгать булып, кыйммәтле машиналар артына утырмыйча яшәвебез - ахирәтне өстенрәк куюдан килә, чөнки халыкның монда төп йорты булып - мәчет санала", - диде авыл аксакаллары безгә.

Козлов Йосыф Акдәс улы - тумышы белән Урта Әләзәннән, Октябрьскоеның Урта мәчете имамы. Бирегә аны авыл картлары тәравих намазында Коръән укуын ишеткәч Күзнәйдән (Кузнецк шәһәре) чакыртып алганнар. Йосыф хәзрәтнең әтисе Акдәс Козлов та дин эшлеклесе, Күзнәй мәчете имамы. "Мин студент вакытта Россиянең 600 мәчетенә имам җитми иде. Моның җимешләрен 13 ел элек Октябрьскоега күчеп килгәч татыдым. Арада тәһарәт ала белмәүчеләр, намаз турында беренче тапкыр ишетүчеләр дә бар иде. Хәзер Аллага шөкер, җомга, тәравих намазларында өч мәчет тә халык белән шыгрым тула. Авылда биш тапкыр намазга чакырып азан әйтелә, никах, балага исем кушу, мәетне озату дини кануннарга туры китереп башкарыла", - дип сөйләде Йосыф хәзрәт. Хәләл җефете Гөлшат белән алар Билал исемле ул үстерәләр. Гаиләләрендә ислам традицияләренә тугрылык саклап яшиләр. Билал - исламда беренче азан әйтүче кеше булган. Йортларын саклаучы эткә дә мөселманча исем кушканнар - Катмир. Анысы җәннәткә кергән бер хайван икән. Өендәге кебек дини тәртипне Йосыф хәзрәт бөтен авыл буенча күрергә хыяллана. Ике ел элек кенә авылга бердәнбер хәләл азык-төлек, дини әдәбият һәм башка төр кирәк-яраклар сатучы лаука (кибетне биредә шулай дип атыйлар. - Авт.) ачып җибәргән. Хәләл казылыкны Самара өлкәсендәге Похвистнево районыннан, башка товарларны исә Казанга ук барып алалар. Халык бигрәк тә яратып баш яулыклары, хәләл хушбуйлар, шәмаилләр сатып ала икән. "Иң мөһиме - монда хәмер сатылмый. Тора-бара башка кибетләр дә хәләлләшеп китмәсме", - диде авыл җитәкчесе Нәим Ляпин.

Хәер, Октябрьское бай тарихлы да, уңган халыклы да авыл ул. Аның тарихи урыннарын йөреп хозурланып туялмаслык: Әсәки тавы, Таш-Елга, Ерыклей... Авылдан байтак кына күренекле шәхесләр дә чыккан: Советлар Союзы Герое, автоматчы Б.М. Еналиев, техник фәннәр докторы, профессор Х.Ш. Зәбиров һ. б.

Зәбировлар - Октябрьскоеда иң күренекле нәселләрнең берсе. Аларның бер вәкиле Рәфыйк Зәбиров - умарта тотучы буларак дан тота. "Үземне белгәннән бирле умарта асрыйм. Бабайлар, аларның бабайлары да умарта тоткан", - дип сөйләде ул. Рәфыйк әфәнденең умартасы 22 башка җыела икән. Шулардан сезонына алынган 500 кило балның 20 килосын ул кышка калдыра. Калган балны килосын 300 сумнан сатып бетерә икән. "Мәшәкате күп булса да, табышлы хезмәт, тормыш итәргә ярдәме тия, Аллага шөкер!" - диде ул.

Еналиевлар гаиләсе дә авылның тоткалары дисәк, ялгыш булмас. Күптән түгел алар авыл янында ял базасы оештырганнар. Еналиевлар гаиләдә алтау: Рәшидә белән Раифә ханымнар эшкуарлар. Рәшид, Рафаэль, Наил, Камил - инде 15 ел йорт җиһазлары җитештерәләр һәм авыл хуҗалыгы тармакларында хезмәт куялар. Аларның Күзнәйдә урнашкан "Элна мебель" фабрикаларында ясалган җиһазлар хәзер Россиянең төрле почмакларына таратыла!


Октябрьское авылы безгә тагын чишмәләре, йөзәнгеләре (җирле халык пешерә торган көлчә) һәм милли бизәкле йортлары белән дә истә калды. Милләттәшләребезнең Татарстаннан читтә әнә шулай гөрләтеп, үз телебездә сөйләшеп, ислам кануннарын үтәп яшәүләре сокландыргыч хәл. Моның сере турында алар: "Без дөнья кумыйбыз, телебезне, гореф-гадәтләребезне исә - динебез аша саклап калдык", - диләр...

*Гөлназ ГАЛИМҖАНОВА,*
*Рәмилә ГАЗИЗУЛЛИНА.*
*Казан-Пенза.*
*Авторлар фотосы.*

# КАПКА ТӨБЕНДӘ

(бәян-вәгазь)

*(Ахыры. Башы газетабызның 5-6, 8-9 нчы саннарында.)*



Айдар да аның янына утырып, аркасы белән капкага сөялде дә, башын өскә күтәреп күккә карады. Яп-якты ай әйләнәсендә күк гөмбәзен матур бизәп чәчелгән йолдызлар, тылсымлы җемелдәп, нәрсәдер әйтәләр иде сыман. Тик нәрсә?

- Шәһәрдә йолдызлар болай ук яхшы күренми, - дип әкрен генә әйтеп куйды Айдар. - Шуңадыр, авылга кайткач, мин аларга карап сокланып туя алмыйм. Шушы санап бетергесез бихисап йолдызлар янына нигәдер күтәреләсем килә минем...

- Вакыты җиткәч, күтәрелерсең әле, - дип җавап бирә Гарәфетдин бабай. -Ничәмә-ничә ел яшәгән күпме кешенең җаннары шушы йолдызлар кебек бихисап күп хәзер ахирәттә. Алар кайчандыр җир йөзендә яшәделәр, тәкъдир сынауларын үтеп, ахирәткә, мәңгелеккә күчтеләр. Кайсыларыдыр ахирәттә шатланып "җемелди", кайсыларыдыр - утлы күмер кебек янып, гөнаһларын кара төтен булып көйрәтеп чыгара. Аллаһ хозурына чиста җаннар гына кабул ителә шул. Ә бу җирдә безгә пычрак ябышырга гына тора. Чиста булып калуы бик кыен.

Бу мизгелдә күккә карап бабасын тыңлаган Айдарга күк гөмбәзендәге исәпсез йолдызлар бакыйлыкка ашкан җаннар булып тоелды. Өстән аянычлы, кызганычлы карап, "җаннар", галәмне яңгыратып, кычкыралар иде сыман:

- Сездә - җирдә - инде күптән яңгыр яумый, ә без монда бик зарыгып дога көтеп торабыз. Их, бер рәхәтләндереп дога кылсалар икән безгә! Нигә шулай бик ваемсыз яшәп, искә алмыйсыз сез безне, туганнар!".

Кайбер җаннарның хәле бераз гына арурак булса да, алар өчен дә шифалы изге дога бик тә тансык, кадерле. Әмма җаннарның күпчелеге догалардан күптән мәхрүм. Аларның җирдә яшәүче туганнары инде байтак вакыт мәрхүмнәрен искә алмый, ахирәттәге якыннарының рухларына шәфкать, ярлыкауны сорап, Раббыларына, күз яшьләрен түгеп, мөрәҗәгать итми...

Көн дәвамында барлы-юклы дога кылучы кешеләрне эзләп йөргән фәрештәләр кайгылы хәлдә күккә аша. Үлем фәрештәсе исә яңа гына, Аллаһы Тәгалә боерыгын үтәп, шушы авылда яшәүче ике кешенең җанын ала. Шуларның берсе - авыл имамы Кәримулла хәзрәт. Ә икенчесе - Мәсхүт абый. Күк гөмбәзе бер мәлгә яктырып ала. Бу рәхмәт фәрештәләре Кәримулла хәзрәтнең җанын бик хөрмәтләп вә зурлап Аллаһ хозурына алып менеп киттеләр. Шуннан соң тылсымлы нурлар күктә җәелмәде. Пенсиягә чыкмыйча, мәчеткә керергә өлгерми калган Мәсхүт абыйның җаны хафаланган, куркуга сабышкан хәлдә күккә күтәрелде.

Гарәфетдин бабай нәрсәдер сизенгәндәй, йолдызлы күккә хәвефле карап, оныгына әле генә әйткән сүзен кабатлап, фикерен җөпләп куя:

- Вакыты җиткәч, барыбызга да шунда күтәреләсе. Ничек кенә теләсәк тә, шушы җирдә беребез дә мәңгегә кала алмый. Без әбиең белән инде олы яшьтә, күпме калгандыр бу дөньяда яшәргә. Әмма шуңа куанам: без -иманлы, Аллаһыны хөрмәтләп, санлап яшәдек, булдыра алганчы гыйбадәтен кылдык. Әле синең кебек иманлы дәвамчыбыз булуга да бик сөенәбез. Димәк, ахирәттә догага тилмереп ятмабыз. Кыласыңмы безнең өчен дога?

Айдар сөйкемле елмаеп бабасына карый да, аның кулын тотып йомшак кына әйтә:

- И бабай, әлбәттә инде кылам!

Гарәфетдин абый да елмая һәм канәгатьләнү хисе илә әйтә:

- Рәхмәт, улым, бик рәхмәт, Аллаһ разый булсын үзеңнән. Тик минем тагын бер гозерем бар бит әле сиңа... Син, улым, Мәрфуга апаңны да онытма, яме... Дога кылганда аны да искә ал.

- Ә ни өчен нәкъ менә Мәрфуга апаны? - дип аптырый Айдар.

Гарәфетдин бабай бераз каушый, әмма эчке дулкынлануын сиздермәскә тырышып, әйтә:

- Чөнки мин аны... ни... җәллим... Улы туры юлга басып, аны искә алыр микән? Белмим шул, бик шөбһәле. Ә Мәрфуга апаң ул ихласлы, тырыш. Авыр булса да, дөнья дилбегәсен дә тартты, намазын да укыды. Ул үзенә дога кылучы булуга лаеклы.

Айдар бабасының кулын кысып ала да егетләрчә күтәренке тавыш белән әйтә:

- Ярар, бабай, борчылма! Аңа да кылырбыз дога. Миңсылу апа белән җизни өчен дә сорарга кирәк. Аллаһы Тәгалә бит гафу итүче, тәүбәләрне кабул кылучы. Әле җизни дә аракыдан арыныр, берзаман чиста киемнәрен киеп, Җомга намазына мәчеткә килер, бөтенләй яңача яши башлар. Нишләптер мин моңа ышанам.

- Дөрес, улым, бик дөрес әйтәсең, - дип ризалаша Гарәфетдин бабай. -Өмет ул һәрвакыт булырга тиеш. Әйдәле, балакаем, менә хәзер үк бер дога кылыйк, үзең ни телисең, сора Аллаһыдан.

- Мин бик оста түгел дә инде... - дип шикләнеп куйган егеткә бабасы әйтә:

- Ничек булдырасың - шулай сора. Исәннәр өчен дә сорыйк, әрвахларны да шатландырыйк.

Бабай белән онык кулларын догага күтәрә. Бераз аптырап калган Айдар берничә секунд дәшмичә тора, аннары "Бисмилла"сын әйтеп Аллаһыга мөрәҗәгать итә:

- Йә Аллаһ, йә Раббым! Сиңа рәхмәтебезне белдерәбез, шөкер кылабыз. Безгә биргән ризыкларың, сәламәтлек, иман - башка нигъмәтләрең өчен, исән-сау булган әти-әнием, әби-бабаем, туганнарым, дусларым өчен, йә Раббым, Сиңа шөкер итәм. И Раббым, Син безгә якты кояшлы көннәр, тыныч төннәр бирәсең, шушы дөньяга урнаштырып, гомер бүләк итеп, укырга, эшләргә, яшәргә мөмкинчелек бирәсең. Йә Раббым, шушы нигъмәтләреңнән аерма, аларның бәрәкәтен, куанычын күрергә насыйп әйлә.

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# КАПКА ТӨБЕНДӘ

(бәян-вәгазь)

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

Йә Раббым, миңа да, барлык туганнарыма, шушы авыл халкына да хәерле, файдалы гыйлем биреп, Үзеңә гыйбадәт кылып яшәргә насыйп ит. Безнең гөнаһларыбызны ярлыка, төрле зыян-зарардан, бәла-казалардан сакла, ярдәмеңнән ташлама.

Йә Раббым, вафат булган туганнарыбызның, авылдашларыбызның, бездән дога көткән әрвахларыбызның гөнаһларын гафу ит. Аларның изге гамәлләрен, гыйбадәтләрен кабул ит. Ахирәттәге хәлләрен җиңеләйтеп, шушы дога аша рухларын шатландыр, ахыргы урыннарын Җәннәттә кыл...

Айдар дога кыла башлауга ук Гарәфетдин абыйның тамагына төер тыгылды. Ничек кенә сабыр итәргә тырышса да, онытгы "әбибабаем өчен шөкер итәм" диюгә, ул, күңеле тулып, тавышсыз гына елый башлады. Догада үзен искә алганнары өчен генә түгел, ахирәтнең якынлыгын тойганга, шунда китсә, аны искә алып, рухына дога кыла алырлык иманлы, пакъ күңелле оныгы булганга да уйланып та, сөенеп тә елый иде ул. Хәер, Айдар аның күз яшьләрен күрмәде: ул елмаеп, төнге күккә карый иде. Догасын кылып бетерүгә, аның кальбе күктәге йолдыз-җаннарның дәррәү "Әәмиин!" диюен ишетте, күңел күзе шул җаннарның сөенечле балкып, җемҗем килеп шатланганнарын күрде. Бу мизгелдә күктә бәйрәм рухы хөкем сөрде. Дога кылучының җиде буын әби-бабалары горурланды. Фәрештәләр дә тантана итте. Саф күңелле яшь егетнең догасы игътибарсыз калмады. Авыл өстенә Аллаһының бәрәкәте яуды, халык корылыктан имин булды, аның зарарыннан котылды. Монда Яратучы яңа имам тәкъдир кылды, күп кешене ярлыкады, күңелләрен Иман нуры белән нурландырды, тугры юлга бастырды - Үз колларын зурлады.

Баксаң, барысы да бик гади икән: бөек Аллаһ безне зурласын өчен, Аны Үзен ихластан зурларга кирәк. Кем белә, бәлки, һәр туар таң, калкып чыккан кояш яктысы, шифалы яңгыр, су, ризык, һава бер ихласлы мөэминнең кабул булган догасы бәрабәренә безгә биреләдер. Әмма шушы нигъмәтләрнең Хуҗасы белән элемтәдә булучылар гына, шөкер итә белүчеләр генә Аның ризалыгын алырлар, җаннарын изгелек белән сугарып, Аллаһ рәхмәте яңгырында чыланып, рухи корылыктан котылырлар, шул сәбәпле бу дөньяда Бәхет юлын табып, күңел тынычлыгына ия булырлар, ахирәттә исә бәхетлеләр - Аллаһ Җәнәбел Хак бәндәләре җыелган урында - Җәннәт бакчаларында калырлар. Мәңгегә...

***Ришат КУРАМШИН,***
***Кукмара мәдрәсәсе мөдире***



# Яшьлекнең кадерен белик!

**Яшьлек - ул шундый вакыт: Аллаһы Тәгалә тарафыннан кешенең төрле яклап сыналган чагы. Ул көч һәм куәткә бай, шул ук вакытта дөнья рәхәтлекләре, байлыклары нәфесне төрле яклап үзенә тартып торган чак.**

Ә шайтан шуннан файдаланып, кешене туры юлдан тайпылдыру, Аллаһка гыйбадәт кылудан тыю өчен бар көчен сала. Күпләр шайтанның ятьмәсенә эләккәннәрен сизми дә калалар һәм аның күрсәтмәләре буенча эш кыла башлыйлар.

Без күреп торабыз: бүгенге көндә күпчелек яшьләр җан тынычлыгын, булсын ул авыл яшьләре, булсын шәһәр яшьләре, дискотека, концерт, кино, ресторан, кафе, сауна, төрле клублардан табалар. Шулай итеп алтын, бриллианттан да кадерлерәк вакытларын әрәм итәләр. Күпләрнең киенү, сөйләшү, тормышта үз-үзен тоту рәвеше, гомумән, Исламнан ерак тора. Гыйлем алып, Коръән һәм Сөннәт буенча яшәргә тырышучылар, кызганыч, сирәк.

Кайбер яшьләр өстән генә фикер йөртеп әйтәләр: нишләп Аллаһ безгә үзебез теләгән бөтен гамәлләрне дә кылырга рөхсәт итмәде? Андыйларның шундый уйлаларын бәләкәй балалар фикерләве белән чагыштырырга булыр иде. Аларга да бит әти-әниләре көне буе уйнарга рөхсәт итми, ә уеннан тыш нәрсә белән булса да шөгыльләнүен контрольдә тотып тора: дәрес хәзерләү, өйдәге эшләрдә булышу һ. б. Әтиәни баланы тәрбияли, ашата-эчертә, киендерә, ә авырып китте исә, ниндидер тәмсез дарулар, уколлар белән дәвалый. Әмма күп балалар бу тырышлыкларны күрми дә, аңлап та җиткерми. Ә күпләр ата-аналарын дошман итеп күрәләр. Әлбәттә, үсеп җиткәч, тәҗрибә туплангач, алар ата-ананың нинди зур көч түккәнен, хәтта үзләреннән дә ныграк кайгыруларына төшенәләр. Ә Аллаһы Тәгалә безгә әти-әнигә караганда да күпкә мәрхәмәтлерәк. Шуны истән чыгармаска кирәк: Аллаһ юлында булып без бу дөньяда гына түгел, мәңгелек бәхеткә дә ирешәбез. Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә әйтә: "Сез җыйган (дөнья малы) бетәчәк, Аллаһ катындагылар исә мәңгелек. Һичшиксез, сабырчыдам булганнарга, иң гүзәл гамәлләренә күрә, яхшы әҗер бирербез" ("Нәхел (Бал корты)" сүрәсенең 96 нчы аяте).

Без күрмибезме әллә, Аллаһ тыйган гамәлләрне кылучыларның ахыргы сулышлары ничек тәмамланганын. Аллаһы Тәгалә Коръәндә: "Без бу хәтәр җәзадан (җәһәннәмнән) алда (фани дөньяда) аларга җәзалар (әсирлек, кытлык, хасталыклар, дөньяви авырлыклар) бирербез. Бәлки, алар тәүбәгә килеп, иман китерерләр" ("Сәҗдә" сүрәсенең 21 нче аяте), - ди.

Аллаһы Тәгалә безгә тәмле тәгамнар белән ризыклану, матур кием кию, бу дөньяның матурлыклары белән ләззәтләнү, ял итүне бер дә тыймый. Әлбәттә, шәригать кануннарыннан чыкмаганда. Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә әйтә: "Әйт син: "Бәндәләре өчен Аллаһ яралткан зиннәтләрне вә саф ризыкларны кем хәрам кылды? - диген. - Алар фани дөньяда иман китергәннәр өчен, аеруча Кыямәт көнендә мөэминнәрнекедер. Менә Без мәгълүматлы халык өчен аятьләребезне шулай ачыклыйбыз"" ("Әгъраф (Пәрдә, калкулык)" сүрәсенең 32 нче аяте).

Күп кешеләр омтылган дөнья байлыклары миражга тиң, тамагыбыз кипкәндә ул безгә ерактан су кебек күренә, ә инде янына барыйк дисәк, без анда бернәрсә дә булмаганын күрәбез. Яшьләр гыйбадәт кылуны, Аллаһ кушканча яшәүне соңгарак, "картайгач"ка калдырмасалар иде. Яшь вакытта кылган гыйбадәт яшь була, картайгач кылган гыйбадәт карт була. Яшь вакытта алган тәрбия, белем ташка уеп язган кебек, ә картайгач алган белем суга язу белән бер, дип юкка гына әйтмәгәннәрдер. Шунысы бар бит әле: кем картлык яшенә барып җитә? Тирә-ягыбызга күз салсак, күпме безнең янда картлар? Кабер ташларыннан туган һәм үлгән елларын карасагыз, сез күпләрнең картайганчы бу дөньядан китеп барганнарына ышанырсыз. Шуның өчен дә гыйбадәт кылуны картлыкка калдыру ахмаклык булыр иде. Халкыбызның иң күренекле затларының берсе Ризаэддин Фәхреддин дә: "Акылы камил булган кеше дингә килмичә калмас", - дип әйткән бит. Әллә без - яшьләрнең акыллары камил түгелме? Алай дисәң, һәр икенче яшь кешедә диплом бар бүген. Әле берәү генә дә түгел.

Бу дөньяда бөтен әйбер капма-каршылыкта: яхшылык - начарлык, сөенеч - кайгы, җиңеллекләр - авырлыклар, сәламәтлек - чир, яшьлек - картлык, көлү - елмаю, белемлелек - наданлык, байлык - ярлылык, ямьсезлек - матурлык, дәрәҗә - түбәнлек, ярату - нәфрәт һ. б. Ә киләсе дөньяда шушыларның тискәреләре өчен дә җавап бирәсе булачак.

Пәйгамбәребез (сгв) кечкенәдән үк үзенең яхшы холкы белән аерылып торган. Аның янында күп йөргән, Исламны таратуга зур көч куйган сәхәбәләр дә - яшьләр булган. Аларның күбесенә нибары 17-35 яшь булган. Яшьлектә кылган гыйбадәтнең зур дәрәҗәсе турында Пәйгамбәребез (сгв) дә әйтеп киткән: "Кыямәт көнендә Аллаһның күләгәсеннән башка күләгә булмаганда, бары тик җиде төрле кеше генә Аллаһның күләгәсе астында булыр, шуның берсе бәләкәйдән үк гыйбадәттә булган яшь кеше".

Тагын бер хәдисендә Мөхәммәд (сгв): "Биш әйберне вакытында файдалан: яшьлегеңнән картлык, сәламәтлегеңнән авыру, байлыгыңнан хәерчелек, буш вакыттан мәшәкать, тормышыңнан үлемең килгәнче", - ди.

Вакытыбызны Аллаһы Тәгалә Үзе риза булырдай итеп үткәрергә насыйп итсен. Әмин.

***Сөмбел ШӘРИФУЛЛИНА,***
***КФУ студенты***

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 8.09.12 | 4:32 | 6:02 | 13:02 | 17:13 | 19:19 | 20:49 |
| Якшәмбе | 9.09.12 | 4:34 | 6:04 | 13:02 | 17:11 | 19:16 | 20:46 |
| Дүшәмбе | 10.09.12 | 4:36 | 6:06 | 13:02 | 17:10 | 19:14 | 20:44 |
| Сишәмбе | 11.09.12 | 4:38 | 6:08 | 13:02 | 17:08 | 19:11 | 20:41 |
| Чәршәмбе | 12.09.12 | 4:40 | 6:10 | 13:02 | 17:06 | 19:08 | 20:38 |
| Пәнҗешәмбе | 13.09.12 | 4:42 | 6:12 | 13:02 | 17:05 | 19:06 | 20:36 |
| Җомга | 14.09.12 | 4:44 | 6:14 | 13:02 | 17:03 | 19:03 | 20:33 |
| Шимбә | 15.09.12 | 4:45 | 6:15 | 13:02 | 17:01 | 19:00 | 20:30 |




«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 10 (153) чыгарылыш.
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** 9415.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 6 сентябрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга куллванудан сакланыгыз!**